РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
НИЖНЕКАМСКИЙ
ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
пр. Строителей, д. 12, г. Нижнекамск, 423570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА
ШӘҺӘР СОВЕТЫ
Төзүчеләр пр., 12 нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

Тел./факс: (8555) 42-42-66. E-mail: Gorsovet.Nk@tatar.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

2019 елның 7 ноябре № 40

Түбән Кама шәһәр Советының
«Түбән Кама муниципаль районы Түбән Кама шәһәре муниципаль берәмлегенең шәһәр төзелешен проектлаштыруның җирле нормативларын раслау турында»
2017 елның 15 сентябрендәге 24 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясы, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Түбән Кама шәһәре Уставының 6 статьясы нигезендә, Түбән Кама шәһәр Советы

КАРАР БИРӘ:

1. Түбән Кама шәһәр Советының «Түбән Кама муниципаль районы Түбән Кама шәһәре муниципаль берәмлегенең шәһәр төзелешен проектлаштыруның җирле нормативларын раслау турында» 2017 елның 15 сентябрендәге 24 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

Түбән Кама муниципаль районы Түбән Кама шәһәре муниципаль берәмлегенең шәһәр төзелешен проектлаштыруның җирле нормативларында (карарга кушымта):

Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Түбән Кама шәһәренең шәһәр төзелешен проектлаштыру буенча җирле нормативларының 6.1.7 пунктындагы 2 җөмләсен үз көчен югалткан дип танырга;

Түбән Кама муниципаль районы Түбән Кама шәһәренең шәһәр төзелешен проектлаштыру буенча җирле нормативларга 2 нче кушымтада:

29 абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Кызыл линияләр - гомуми файдаланудагы территорияләр чикләрен билгели торган һәм территорияне планлаштыру документларында билгеләнергә, үзгәртелергә яки юкка чыгарылырга тиешле линияләр».

Түбән Кама шәһәре Мэры А.Р. Метшин